**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**Янгасалского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Центральная, 1, с.Б.Янгасала, 422832
тел. (8277) 3-55-22 факс: (8277) 3-55-22
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ОКПО 93064624 ОГРН 1061672003414
ИНН/КПП 162204588/162201001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
***Кама Тамагы***
**муниципаль ра йоны**
**Янасала авыл жирлеге**
**Башлыгы**

Њзђк урам, 1, Яћасала авылы, 422832,
тел. (8277) 3-55-22 факс: (8277) 3-55-22
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ОКПО 93064624 ОГРН 1061672003414
ИНН/КПП 162204588/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**23 ноябрь 2021ел** **№2**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлегенең Олы Яңасала авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 3 декабрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлегенең Олы Яңасала торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясе, Олы Яңасала авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Олы Яңасала авылында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- җәйге чорда территорияне чабу(килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Олы Яңасала авылындагы 2нче номерлы  чишмә территорияләрен төзәтү һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр башкару);

- урам утларын төзекләндерү ( энергия саклаучы лампалар сатып алу);

- Тау асты урамы буенча елга үзәнен чистарту (транспорт хезмәтләре, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

"ӘЙЕ"                    “ЮК”

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга) :

ТР, Кама Тамагы районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк урамы, 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, Клуб урамы, 14 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге**
**башлыгы** **И.Х.Шиһабеев**